**Тәтеш муниципаль районында торак урыны мәйданының исәпкә алу нормасы һәм социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданы бирү нормасы турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьяларын гамәлгә ашыру, дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районында гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында торак урыны мәйданының гомуми мәйданы белән тәэмин итү дәрәҗәсе гаиләнең бер әгъзасына 18 кв.метрдан да ким булмаган гомуми мәйданы күләмендә билгеләнә торган торак урыны мәйданының исәп нормасын билгеләргә.

2. Социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасын, социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннары белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районында бер гражданга торак урыны гомуми мәйданының 18 кв.метры күләмендә билгеләргә.

3. Торак урынының гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.

4. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының «авыл җирлегендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә алу өчен торак урыны гомуми мәйданының исәпкә алу нормасы турында» 12.08.2009 ел, № 588 карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Ф. Әхмәтшинга йөкләргә.

Җитәкче А.Б.Семенычев